Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Колшәрип авыл Советы

КАРАРЫ

23 апрель 2024 ел № 84

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертү, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлеге Уставының XIV бүлеге, 2023 елның 20 ноябрендәге гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча, Әлмәт шәһәр прокуратурасының 2023 елның 7 августындагы 02-08-02/855 номерлы күрсәтмәсен карап

Колшәрип авыл Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлеге Уставына (Колшәрип авыл Советның 2012 елның 6 июлендәге 52 номерлы, 2013 елның 28 августындагы 74 номерлы, 2014 елның 18 декабрендәге 115 номерлы, 2016 елның 12 маендагы 23 номерлы, 2017 елның 12 апрелендәге 35 номерлы, 2018 елның 4 июлендәге 54 номерлы , 2019 елның 14 маендагы 72 номерлы, 2020 елның 12 маендагы 88 номерлы, 2021 елның 27 сентябрендәге 22 номерлы, 2023 елның 19 маендагы 66 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) кушымта нигезендә түбәндәге үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрергә.

3. Әлеге карарны Колшәрип авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус стендларда халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Әлмәт районы, Колшәрип авылы, Тукай урамы, 50 йорт, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясының 8 өлешенә ярашлы рәвештә үз көченә керә.

5. Бу карарның үтәлешен контрольдә тоту Колшәрип авыл җирлеге Башлыгына йөкләргә.

Колшәрип авыл җирлеге башлыгы А.Ф. Кәшәфетдинов

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Колшәрип авыл Советының
2024 елның 23 апрель
84 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Колшәрип авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү

1) 5 статьяның 1 өлешендәге 12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12) балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү, яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программаларны эшләү, гамәлгә ашыру, торак пунктта яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыру һәм гамәлгә ашыру;»;

2) 24 статьяның 7.1 өлеш түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«7.1. Җирлек Советы депутаты «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм коррупциягә каршы көрәш максатларында башка федераль законнар белән билгеләнгән бурычларны, чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителә, әгәр мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү, булган хәлләр бәйсез тикшерү тарафыннан күрсәтелгән затларга «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273 - ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясының 3-6 өлешләрендә каралган тәртиптә танылса»;

3) 37 статьяны түбәндәге эчтәлектәге 6 өлеш белән тулыландырырга:

«6. Җирлек башлыгы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон федераль законнар белән билгеләнгән бурычларны, чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителә, әгәр мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү, булган хәлләр бәйсез тикшерү тарафыннан күрсәтелгән затларга «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273 - ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясының 3-6 өлешләрендә каралган тәртиптә танылса»;

4) 43 статьяның 1 пункты 6 пунктчасы сигезенче абзацын төшереп калдырырга;

5) 43 статьяның 1 пункты 9 пунктчасы өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча чаралар оештыра һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү, яклау чараларын эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программаларны эшләүдә, гамәлгә ашыруда, торак пунктта яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыруда һәм гамәлгә ашыруда катнаша;»;

6) 43 статьяның 2 пункты түбәндәге эчтәлектәге абзацлар белән

тулыландырырга:

«-муниципаль хокукый актларны игълан итү, муниципаль берәмлек халкына рәсми мәгълүмат җиткерү өчен басма массакүләм мәгълүмат чарасы һәм челтәр басмасы булдыра;

-халыкара һәм тышкы икътисади элемтәләрне «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашыра.»;

7) 56.1 статьясында:

а) 1 өлешнең 1 пунктын «федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш» дигән сүзләр белән тулыландырырга;

б) 1 өлешнең 2 пунктында «яки белә торып дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүматны күрсәтүне» сүзләр белән алыштырырга «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, белә торып тулы булмаган мәгълүматны күрсәтүне яки белә торып дөрес булмаган мәгълүматны күрсәтүне;

в) 2 өлешне «федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш» дигән сүзләр белән тулыландырырга;

8) 63 маддәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«63 статья. Муниципаль хокукый актларны игълан итү һәм аларның үз көченә керү тәртибе»**

«1. Кеше һәм гражданның хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар, нигез салучы булып торган оешмаларның хокукый статусын билгеләүче муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләр рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

2. Муниципаль норматив хокукый актның, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүнең рәсми игълан ителүе булып тора:

1) Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында тулы текстны рәсми бастырып чыгару (https://pravo.tatarstan.ru) массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык 17.12.2013 Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт (Роскомнадзор) яисә «Альметьевский вестник» газетасында, ПИ № 16-00933 массакүләм мәгълүмат чарасы сыйфатында теркәлү турында таныклык 27.12.2012 Татарстан Республикасы буенча мәгълүмати технологияләр, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт тарафыннан бирелгән;

2) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштыру (https://www.almetevsk. tatarstan.ru).

3) Авыл территориясендә урнашкан мәгълүмат стендында: Колшәрип авылы, Тукай, 50 йорт урнаштыру.

3. Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына гражданнарның керүен тәэмин итү өчен торак түбәндәге адрес буенча пунктның башкарма комитеты бинасында урнашкан «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренә тоташу пункты эшли: Татарстан Республикасы, Әлмәт районы Колшәрип авылы, Тукай урамы, 50 йорт.

4. Муниципаль норматив хокукый актлар, җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр, муниципаль хокукый актлардан яки Федераль закон белән чикләнгән мәгълүматлар булган аерым нигезләмәләрдән тыш, имзаланганнан соң 10 көн эчендә игълан ителә.

5. Җирлек Советының салымнар һәм җыемнар турындагы норматив хокукый актлары Россия Федерациясе Салым кодексына ярашлы рәвештә үз көченә керә.

6. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелмәгән муниципаль хокукый

актлар, әгәр акт белән башкасы билгеләмәсә, имзаланган көннән үз көченә керә.

7. «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә тиешле сайтларның домен исемнәре һәм аларны массакүләм мәгълүмат чаралары буларак теркәү турындагы мәгълүматлар күрсәтелгән вакытлы матбугат басмалары, челтәр басмалары исемлеге, аларда муниципаль хокукый актлар, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләр игълан ителә, җирлек башлыгының хокукый актын бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерелә.».

Колшәрип авыл җирлеге башлыгы А.Ф. Кәшәфетдинов